# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бутлеровка авыл торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**2025 елның 1 ноябрендәге 2 номерлы**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Уставына туры китереп

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бутлеровка авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндез укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Бутлеровка авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru)бастырып чыгарырга .

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы** **И.Л. Хушанова**